# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Югары Татар Майнасы авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2023 елның 13 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 13 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районы «Майна авыл җирлеге» Югары Татар Майнасы торак пункты территоиясында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш җәю, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5) су башнясы өчен су насосы сатып алу;
6) ДПОны ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 131 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 71 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 71 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Югары Татар Майнасы торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» Югары Татар Майнасы торак пункты территориясында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш җәю, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

5) су башнясы өчен су насосы сатып алу;

6) ДПОны ремонтлау.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Майна авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге башлыгы

Я.Д.Иванов